# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге составына керүче Уразбахты авылында 2025 елга үзара салым кертү турында

№ 1 24.10.2024 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты авылында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге Уразбахты авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр, махсус хәрби операциядә мобилизацияләнгән катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2025 нче елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Уразбахтино торак пунктында урамнарны яктырту лампаларын агымдагы ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Уразбахты торак пунктында чокырларны ремонтлау); Уразбахтино торак пунктында юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Уразбахтино торак пунктында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру 2 шт).

3. Әлеге карарны Уразбахты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Р.Г.Шәйхетдинов